МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№_____1525/о_____

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

«__16___»_______10_______2025__

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 03.07.2025 ел, №822/о боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023, 2024 һәм 2025 елларда җирдән файдалануның һәм төзелешнең генераль планнарына һәм кагыйдәләренә иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздырмыйча гына үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы карары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында» 2025 елның 10 октябрендәге 1495/о боерыгы, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе утырышының 2025 елның 13 октябрендәге 56 номерлы беркетмәсе

нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 3 июлендәге 822/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 6 октябрендәге 1474/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге боерыкның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә «Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар» картасы фрагментында:

территориаль зона – әйләнә-тирә мохиткә аз йогынты ясаучы җитештерү предприятиеләре зонасын (П-2) кадастр номерлары 16:24:160303:4581, 16:24:160303:4589, 16:24:160303:4621, 16:24:160303:4622 булган җир кишәрлекләренә карата транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы (Т) территориаль зонасына үзгәртергә;

территориаль зона – кадастр номеры 16:24:160303:4582 булган җир кишәрлегенә карата транспорт инфраструктурасы объектлары зонасын билгеләргә.

1.2. Әлеге боерыкның 2 нче кушымтасына ярашлы рәвештә «Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр каралган территорияләр» картасы фрагментында:

чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр каралган 2.6 территория составыннан кадастр номерлары 16:24:160303:4581, 16:24:160303:4582 16:24:160303:4589, 16:24:160303:4621, 16:24:160303:4622 булган җир кишәрлекләрен чыгарырга.

1.3. Әлеге боерыкның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә «Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары» картасы фрагментында:

кадастр номерлары 16:24:160303:4581, 16:24:160303:4582 16:24:160303:4589, 16:24:160303:4621, 16:24:160303:4622 булган җир кишәрлекләренә карата урам-юл челтәре зонасы чикләрен үзгәртергә.

1.4. Шушы пунктның 1.1 – 1.3 пунктчаларында күрсәтелгән үзгәрешләрне әлеге Кагыйдәләр составындагы түбәндәге карталарда күрсәтергә:

«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар»;

«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары»;

«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр каралган территорияләр»;

«Территорияләрдән файдаланунының махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы. Махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләре картасы»

1.5. Әлеге Кагыйдәләргә кушымта булып торган территориаль зоналар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерыкның 4 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә (китерелми).

2. Территорияләрне үстерү департаменты Аломерацияләрне үстерү идарәсенең Казан агломерациясен үстерү бүлегенә (Р.А. Мәмәтовага) тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

«Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең координаталары исемлеге булган территориаль зоналар чикләре турындагы белешмәләрне әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.


5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ *
Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының «_16_»__10__
2025 ел, №1525/о___ боерыгына
1 нче кушымта

**«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар» картасы фрагменты**




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

**Ж-1** Индекс территориальной зоны
**1-1** Уникальный номер территориальной зоны
└→ порядковый номер территориальной зоны
└→ порядковый номер границы населенного пункта

| ТӨСЕ | ИНДЕКСЫ | ТЕРРИТОРИАЛЬ ЗОНАЛАР ТӨРЛӘРЕ |
|---|---|---|
| | П-2 | ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТКӘ АЗ ЙОГЫНТЫ ЯСЫЙ ТОРГАН ҖИТЕШТЕРҮ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕ ЗОНАСЫ |
| | Т | ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ОБЪЕКТЛАРЫ ЗОНАСЫ |

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының « 16 » 10
2025 ел, №1525/о боерыгына
2 нче кушымта

**«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр каралган территорияләр» картасы фрагменты**




Шартлы билгеләр

**Условные обозначения:**


Территория, в границах которой предусматриваются требования к архитектурно-градостроительному облику объектов капитального строительства

1.1
Номер контура территории
Номер территории, в границах которой предусматриваются требования к архитектурно-градостроительному облику объектов капитального строительства

№ 2

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының «_16_» _10_
2025 ел, №1525/о__ боерыгына
3 нче кушымта

**«Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары» картасы фрагменты**



**Условные обозначения:**

Подзоны территориальных зон

Подзона улично-дорожной сети